**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» 11 2018 г № 650

Аксубаево

Аксубай муниципаль районы Башкарма
комитетының 2017 елның 24 апрелендәге
№ 261 карары белән расланган " 2017-2021
елларда Аксубай муниципаль районында кече, урта
эшмәкәрлекне үстерү һәм кече формада
хуҗалык итү” программасына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына нигезләнеп,

**Карар бирәм:**

1.Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 24 апрелендәге 261 номерлы карары белән расланган «2017-2021 елларга Аксубай муниципаль районында кече, урта эшмәкәрлекне һәм кече формада хуҗалык итүне үстерү» программасына үзгәрешләр кертергә, «2017-2021 елларга Аксубай муниципаль районында кече, урта эшмәкәрлекне һәм хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү программасының төп чаралары» X. бүлеген 9 пунктын тулыландырырга. киләсе редакциядә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **9. Социаль эшкуарлыкка ярдәм чаралары** | | | | | |
| 9.1 | Эшкуарларга адреслы юридик ярдәм күрсәтү. Социаль эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә хокукый белем бирү. Социаль өлкәдә эшмәкәрлекне әзерләү һәм яңадан әзерләү, квалификацияләрен | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының үзара хезмәттәшлеген җайга салу, яктырту | Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты, юридик бүлек һәм ДКУ «Халыкны | Барлык чорга | Республика һәм җирле бюджет |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | күтәрү. | | эш белән тәэмин итү үзәге” | | |
| 9.2 | Контроль-күзәтчелек органнары белән уртак киңәшмәләр үткәрү | Контрольлек итүче, күзәтчелек һәм хокук саклау органнары эшчәнлеге турында эшкуарларның хәбәрдарлыгын арттыру | Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты | Барлык чорга | Республика һәм җирле бюджет |

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм милек белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Ф. Горбунов